**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1578**
**12.03.2024**

«Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2021 елның 29 октябрендәге 7116 номерлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы халыкларының милләтара элемтәләрен һәм дуслыгын ныгыту һәм шәһәрдәшләрнең ялын оештыру максатларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының муниципаль турын (алга таба – конкурс) 2024 елның март-апрелендә оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Рasларга:

1) конкурс турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча чараларны финанслауны 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 25 000 (егерме биш мең) сум күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                                Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 12 мартындагы
1578 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Мин татарча сөйләшәм»
республика конкурсының муниципаль туры турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының муниципаль туры (алга таба – конкурс) Татарстан Республикасының «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан, «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары:

1) татар телен өйрәнү мотивациясен көчәйтү;

2) татар дәүләт телен куллану өлкәсен киңәйтү;

3) укучыларда гражданлык хисе формалаштыру, патриотизм, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү;

4) сәләтле һәм талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү, балаларның интеллектуаль иҗатын үстерү;

5) татар телендә аралашуны популярлаштыру.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурс 2024 елның 20 мартыннан 27 мартына кадәр үткәрелә. Конкурс түбәндәге этаплардан тора:

1) мәктәп этабы – «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсы кысаларында акция формасындагы чаралар — 2024 елның 10 мартыннан 15 апреленә кадәр;

2) шәһәр этабы - «Күңелләрдә бәйрәм!» йомгаклау чарасы — 2024 елның 25 апреле.

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты конкурс материалларын кабул итә, конкурска йомгак ясый, конкурста җиңүчеләрне бүләкләүне оештыра.

5. Конкурста шәһәрнең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем оешмалары, «Мин татарча сөйләшәм» мәктәп конкурсларында җиңүчеләр катнаша ала.

6. Конкурста катнашу укучыларны һәм яшьләрне татар телендә аралашуга җәлеп итүгә ярдәм итә торган төрле чаралар үткәрүдән гыйбарәт.

7. Бәйгенең мәҗбүри шарты - акциянең (логотип һәм төсләрнең) бердәм стилен, «Мин татарча сөйләшәм» логотибы төшерелгән тарату материалларын, наклейкаларны, «Татар телендә беренче 150 сүзең» буклет-сүзлекне файдалану һәм үткәрелгән чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту.

8. Конкурсның шәһәр этабына мәктәп этабын үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәге бирелгән материаллар нигезендә иң күп балл җыйган катнашучылар чакырыла:

1) катнашучылар саны турында мәгълүмат;

2) тарату материалларының цифрлы фотолары;

3) санын күрсәтеп, татар телендә үткәрелгән чараларның нәтиҗәләренә тасвирлама;

4) җәмәгать урыннарына (даруханәләр, кибетләр, җәмәгать транспорты һ. б.) бару турында мәгълүмат;

5) массакүләм мәгълүмат чараларында басмалардан өземтәләр, сайтларга сылтамалар.

9. Шәһәр этабында конкурста катнашучылар тәкъдим ителгән эшләренә үзанализ буенча оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җавап бирәләр (10 минутка кадәр).

10. Конкурсның шәһәр этабы нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары:

1) татар телен белү дәрәҗәсе;

2) үткәрелә торган чараларның сайланган формаларын нигезли белү;

3) алынган нәтиҗәнең конкурс максатларына һәм бурычларына туры килү дәрәҗәсен бәяли белү;

4) гомуми эрудиция;

5) оригинальлек.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

11. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан биш баллы система буенча бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә.

12. Конкурс нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

13. Шәһәр этабында 4-9 урыннарны алган катнашучылар конкурс лауреатлары булып санала. 2, 3 урыннарны алган катнашучылар конкурсның призерлары булып санала. Конкурсның бәяләү критерийлары буенча конкурста иң күп балл җыйган җиңүчегә «Иң яхшы татарча белүче» («Знаток татарского языка») исеме бирелә.

14. Бәйгенең җиңүчесе, призерлары һәм лауреатлары дипломнар һәм призлар белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева